СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.03.2026 № 8/3

На № ________ от ____________

# КАРАР

## 2025 ел өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап

«2025 ел өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге эшчәнлеге нәтиҗәләре турында» хисапны тыңлап фикер алышкач, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2025 ел өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге эшчәнлеге нәтиҗәләре турында» хисапны игътибарга алырга.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенә тәкъдим итәргә:

2.1 Татарстан Республикасының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасы кысаларында комплекслы чараларны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты белән берлектә гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.2 2026 елда Тукай районы территориясендә массакүләм чаралар чорында җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итәргә.

2.3 Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасында законсыз миграциягә һәм җинаятьчелеккә каршы тору максатыннан, Тукай районында миграция ситуациясен контрольдә тотуны дәвам итәргә.

2.4 Иҗтимагый берләшмәләр, дини оешмалар белән берлектә, экстремистик һәм террорчылык эшчәнлегенә каршы тору өлкәсендә, критик инфраструктура һәм яшәешне тәэмин итү объектларына аерым игътибар биреп, мөмкин булган милләтара конфликтларны булдырмау буенча чаралар үткәрергә.

2.5 Наркоҗинаятьләрне ачыклау, яшерен нарколабораторияләр эшчәнлеген туктату буенча чаралар үткәрүне дәвам итәргә.

2.6 Балигъ булмаганнар арасында, аларны җинаятьчел эшчәнлеккә җәлеп итүгә каршы көрәш максатында, хокук бозуларны профилактикалау чараларын дәвам итәргә.

2.7 Мәгълүмат технологияләрен кулланып кылына торган җинаятьләрне профилактикалау чараларын дәвам итәргә.

3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

3.1 Тукай районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны һәм гражданнарның иминлеген оештыру буенча хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлекне дәвам итәргә;

3.2 Хокук саклау юнәлешендәге (экстремизм һәм терроризм күренешләренә каршы тору, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә) муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны һәм вакытында финанслауны, шулай ук күрсәтелгән программаларның эчтәлеген «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезләмәмләре нигезендә актуальләштерү.

3.3 «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге белән берлектә гражданнарның шәхси иминлеге, акчаларының һәм мөлкәтенең сакланышы мәсьәләләрен аңлата торган материалларны, экстремистик һәм террорчылык юнәлешендәге җинаятьләр әзерләү яисә кылуның билгеле булган фактлары турында хокук саклау органнарына мәгълүмат бирү ысуллары хакында белешмәләрне газетада урнаштыру эшен көчәйтергә.

3.4 Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы бүлеге белән берлектә юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау һәм балаларның юл-транспорт травматизмын профилактикалау буенча уртак чаралар планын гамәлгә ашыруны һәм вакытында үтәүне тәэмин итәргә. Юл челтәрен ГОСТ таләпләренә туры китерү эшен оештыруны контрольдә тотуны катгыйландырырга.

3.5 Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге белән берлектә алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз сату белән шөгыльләнүче затларны ачыклау эшен дәвам итәргә.

3.6 Ирекле дружиналар, «Форпост» яшьләр формированиесе әгъзаларына матди стимул бирү эшен дәвам итәргә.

3.7 Чаралар уздырыла торган урыннарда оператив хәлгә контрольне көчәйтү, хокук бозуларны документлаштыру сыйфатын арттыру өчен, «Имин шәһәр» АПК кысаларында видеокамералар урнаштыру эшен оештырырга. Спорт объектларын, мәдәният учреждениеләрен, мәгариф учреждениеләрен стационар металл детекторлары белән тәэмин итәргә.

4. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

4.1 Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенә мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләр кулланып кылынган җинаятьләрне кисәтү буенча профилактик чаралар үткәрүдә ярдәм күрсәтергә.

4.2 Полиция участок вәкаләтлеләренең административ-торак комплексларында һәм полиция участок пунктларында эшләве өчен тиешле шартлар тудырырга, аларга вакытында капиталь һәм агымдагы ремонт ясарга. Мебель, оргтехника, телефон элемтәсе һәм Интернетка керү мөмкинлеге белән тәэмин итәргә.

4.3 Кече Шилнә торак пунктында полиция участок вәкаләтлесенең эш урынын оештыру өчен яңа бина бүлеп бирү мәсьәләсен «Камский» җитештерү комплексында урнашкан бинаның бөтенләй эшкә яраксыз булуын исәпкә алып хәл

итәргә.

4.4 Үз объектларының террорчылыкка каршы сакланышын саклау максатыннан, Росгвардиягә чыгу белән сак (хәвефле) сигнализация системасы белән җиһазлау мөмкинлеген табарга.

4.5 Районның авыл җирлекләрендә хокук бозуларны профилактикалау программасын үтәү, шул исәптән программа чараларын финанслау чараларын күрергә.

4.6 Районның уку йортларында укучылар белән профилактик эшне дәвам итәргә. Балигъ булмаганнарның үз-үзләрен деструктив тоту фактларын ачыклауга һәм булдырмауга, аларны мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре, алкоголь продукциясен сату өлкәсендәге җинаятьчел эшчәнлеккә җәлеп итүгә аерым игътибар бирергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров